| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2016 Казан ш. № 7-5/т

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә җәмәгать транспортында даими пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими алып баруларны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү” турындагы 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ санлы, “Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы” 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ санлы Россия Федерациясе законнарына, “Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 1995 елның 7 мартындагы 239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына нигезләнеп, “Росия Федерациясендә автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр пассажир транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими алып баруларны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү” Федераль законын тормышка ашыру” турындагы 2015 елның 26 декабрендәге 107-ЗРТ санлы Татарстаны Республикасы законы белән, 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә җәмәгать транспортында даими пассажирлар һәм багаж алып баруга, автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Үз көчләрен югалткан дип санарга:

“Әлмәт шәһәрендә җәмәгать транспортында даими пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында” Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт Комитеты 08 апрелендагы 2011 елның 7-16/т санлы карары кушымтасының 1, 2 пукнтларын;

“Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә гомуми файдаланудагы шәһәр яны автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында” Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт Комитеты 23 августындагы 2013 елның 7-17/т санлы карарының 1 пукнтын.

3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
27.05.2016 № 7-5/т
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәрендә автомобиль транспортында һәм җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багажны даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Транспорт төре | Бер тапкыр транспортта бару һәм 1 урын багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | транспорт салонында билет алган чакта (метрополитен кассасында жетон алган чакта) | озак вакыт куллану билеты белән бару өчен түләү | |
| | | 1 бару[1] | 50 тапкыр бару[2] |
| Автобус | 20 | 18 | 15 |
| Троллейбус | 20 | 18 | 15 |

<1> билгеле бер бәягә барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм;

<2> билгеле бер бәягә ничә тапкыр барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.

Искәрмә. Багаж алып бару бәясе транспортта бару бәясенән аерым түләнелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге